ҖОМГА
29
ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 23 (6745)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Соңгы сәгатьтә

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР КАСТОРНОЕ ШӘҺӘРЕН АЛДЫЛАР

28 нче январьда безнең гаскәрләр, кискен атакадан соң, КАСТОРНОЕ шәһәрен һәм зур тимер юл узелын алдылар. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

КОМСОМОЛГА ҖИТӘКЧЕЛЕКНЕ ТАГЫН ДА КӨЧӘЙТЕРГӘ

Ватан сугышы комсомол оешмалары алдына гаять зур җаваплы бурычлар йөкләде. Аларның рольләре һәм эштә җаваплылыклары тагын да артты. Героик Кызыл Армиябезгә явыз дошманны тизрәк тар-мар итүдә иң күп дәрәҗәдә булышлык күрсәтү һәм бу эшкә барлык союздан тыш яшьләрне туплау комсомолның төп бурычы булып тора.

Большевистик җитәкчелек тәэмин ителгән урыннарда, партия оешмалары комсомол эше белән җитди шөгыльләнгән урыннарда комсомол оешмалары бу бурычны уңышлы үтиләр. Алар, колхоз производствосының һәрбер тармагында үрнәкле эшлиләр. Без аларны колхоз председателе, бригадир, ферма мөдирләре, тракторчылар, комбайнчылар, механиклар һәм башка постларда күрәбез.

1942 нче елны игеннәрне урып-җыюда, дәүләткә ашлык тапшыруда, танклар колоннасы төзү өчен средстволар туплауда комсомол оешмаларының эшеннән уңышлы фактларны бик күп күрсәтергә мөмкин. Хәзер байтак кына комсомол оешмалары язгы чәчүгә әзерлек эшен җәеп җибәрделәр. Без моны Октябрь, Саба районы комсомол оешмаларының эш практикасында аеруча ачык күрәбез.

Ләкин комсомолның барлык оешмалары да үзләренең эшләрен ватан сугышы таләп иткәнчә оештырдылар дип әйтеп булмый әле. Комсомол эшендә байтак кына җитди кимчелекләр яшәп килә. Билгеле, комсомол оешмалары эшендәге кимчелекләрне башлангыч партия оешмаларының комсомол эшенә җитәкчелекне тиешенчә тәэмин итмәүләре, аларга большевистик стильне үзләштерүдә җитәрлек булышмаулары белән дә аңлатырга кирәк. Кайбер партоешмалар комсомол эше белән очраклы рәвештә генә шөгыльләнәләр. Чыгарган карарларның үтәлешен вакытында тәэмин итмиләр. Менә Биектау районы үзәгендәге комсомол оешмаларын алыйк. Биредә комсомол оешмаларының күпчелеге хәзерге көндә үткәрелә торган политик һәм хуҗалык чараларыннан читтә тора. Комсомол сафлары алдынгы яшьләр хисабына үсми. Ә партоешма җитәкчеләре комсомол эшенең шундый таркау хәлдә булуына артык исләре китми. Партия җыелышында, бюро утырышларында комсомол эше турында мәсьәләләр тикшерелми. Нәтиҗәдә, биредәге комсомолецлар игеннәрне урып-җыюда, дәүләткә ашлык тапшыруда һәм башка хуҗалык эшләрендә оештыручылар, инициаторлар була алмыйлар. Шуңа ошашлы фактларны тагын да күрсәтергә мөмкин. Ватан сугышы шартларында мондый хәлгә һич тә түзеп торырга мөмкин түгел.

Комсомол оешмаларының эшләренә башлангыч партоешмалар һәм ВКП(б) райкомнары якыннан торып булышлык итәргә, контрольлек итәргә, «Партия органнары колхозлардагы комсомол оешмаларына, комсомол работникларына карата таләпчәнлекне арттырырга, аларны большевистик җитәкчелек стиленә һәм активлыкка өйрәтергә тиешләр. Колхоздагы, совхоздагы, МТС тагы һәрбер комсомол оешмасының яшьләрне генә түгел, бәлки барлык колхозчыларны да үз артыннан ияртеп баручы сугышчан ячейка булып әверелүенә ирешергә кирәк». («Правда»).

Колхоз комсомол оешмаларының алдында хәзер тагын да җаваплы бурычлар тора. Ул бурыч, 1943 нче елның язгы чәчүенә отлично әзерлекне тәэмин итү, чәчүне үз вакытында яхшы сыйфатлы итеп үткәрү, социалистик ярышны киң җәелдерү, барлык яшьләрне һәм барлык колхозчыларны бу бурычны үтәүгә туплаудан гыйбарәт. Бу эштә һәрбер комсомол оешмасы һәм һәрбер комсомолец үзе башлап үрнәк күрсәтергә тиеш. Партия оешмасы булмаган колхозларда бу бурычларны үтәүдә комсомол оешмасына аеруча булышлык күрсәтергә кирәк.

Башлангыч партоешмалар, ВКП(б) райкомнары комсомол эше белән җитди шөгыльләнергә, аңа һәрбер мәсьәләдә булышлыкны тәэмин итәргә тиешләр.

ИПТӘШ СТАЛИННЫҢ ПРИКАЗЫ ЯҢА ХЕЗМӘТ БАТЫРЛЫКЛАРЫНА РУХЛАНДЫРА

Фронттагы геройлыкларга лаеклы рәвештә

Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказы, баш инженеры иптәш Кадышев булган заводның барлык цехларында да гаять зур күтәренкелек белән өйрәнелә һәм ул героик Кызыл Армия өчен, фронт өчен күбрәк һәм күбрәк продукция җитештерүдә эшчеләр коллективында хезмәт энтузиазмын тагын да арттыра.

Завод декабрьны айлык производство программасын барлык күрсәткечләр буенча бик күп арттырып үтәү белән тәгалләгән иде. Январь аенда эш темплары тагын да арта төште. Электр энергиясе белән тәэмин ителүдә тоткарлыклар булуга да карамастан, январь ае программасы да срогыннан элек шактый арттырып үтәлде дә инде.

Шушы көннәрдә завод коллективы өчен тагын бер шатлыклы вакыйга булды: анда Калинин фронты делегациясе килде. Начальниклары Әҗмитов, Ополонников һ. б. иптәшләр булган цехларда эшчеләрнең фронт делегациясе белән очрашулары үткәрелде. Делегация члены иптәш Төхфәтуллин фронтта Кызыл Армия сугышчыларының явыз дошманга каршы батырларча көрәшүе турында сөйләп, эшчеләрне фронт өчен тагын да зуррак энергия белән эшләргә чакырды. Җанлы һәм шатлыклы булып үткән бу очрашуларда эшчеләр фронттагы геройлыкларга лаеклы рәвештә эшләргә, иптәш Сталинның приказына хезмәт фронтында да героик һөҗүмнәр белән җавап бирергә вәгъдә иттеләр.

Фронт делегациясе членнарына эшчеләр төрле бүләкләр тапшырдылар.

СССР Верховный Советы Президиумы *УКАЗЫ*

РСФСР СОСТАВЫНДА КЕМЕРОВО ӨЛКӘСЕ ТӨЗҮ ТУРЫНДА

Кемерово өлкәсе төзү турында Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы Верховный Советы Президиумы тарафыннан кертелгән тәкъдимне расларга. Аның үзәге Кемерово шәһәрендә була.

Кемерово өлкәсе составына түбәндәгеләрне кертергә: Новосибирск өлкәсе составыннан бүленгән Кемерово, Сталинск, Прокопьевск, Анжеро-Судженск, Белово, Киселевск, Ленинск-Кузнецкий, Осинники, Тайга шәһәрләре һәм Анжеро Судженский, Барзасский, Беловский, Гурьевский, Зырянский, Ижморский, Кемеровский, Киселевский, Крапивинский, Кузедеевский, Кузнецкий, Ленинск - Кузнецкий, Мариинский, Мыскин, Прокопьевский, Таштагольский, Тисульский, Титовский, Топкинский, Тяжинский, Чебулинский, Юргинский һәм Яшкинский районнары.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе **М. КАЛИНИН.**

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре **А. ГОРКИН.**

Москва, Кремль, 26 январь, 1943 ел.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

28 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

28 нче январьга каршы төндә Көньяк-Көнбатыш, Көньяк, Төньяк Кавказ, Воронеж, Волхов һәм Ленинград фронтлары гаскәрләре элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Дон фронты гаскәрләре дошманның таркау группаларын кыруны дәвам иттерделәр. Сталинградның үзәк өлешенә якынрак булган районда немецлар аз гына ут каршылыгы күрсәттеләр. Пленга бирелүчеләр саны сәгать саен арта. Тагын бер генерал, 3 полковник, 4 подполковник һәм башка өлкән офицерлар пленга бирелделәр. Сталинградтан төньяктарак совет частьлары дошманны кысырыкладылар һәм аның җанлы көчләрен кыруны дәвам иттерделәр. Бик күп трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 46 танк, 214 орудие, 583 пулемет, 5.890 автомашина, бер бронепоезд һәм төрле әйберләр тутырылган 20 склад бар.

* * *

Көньяк фронт гаскәрләре һөҗүм алып бардылар, ә көчләрнең бер өлеше белән дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Н-че часть, немецларның флангларыннан әйләнеп үтеп, кинәт удар белән халык яши торган бер пунктка бәреп керде һәм аны алды. Бер бронемашина, 3 орудие, 14 пулемет, танкка каршы ата торган 8 мылтык, фураж склады һәм корал склады кулга төшерелде. Икенче бер участокта дошманның контратакасы кире кайтарылды. Немецларның 2 танкысы һәм бер ротадан артык пехотасы юк ителде.

* * *

Көньяк-Көнбатыш фронтта пехота белән бергә хәрәкәт итүче совет танкистлары халык яши торган 2 пунктны алдылар. Немецларның бер батальоны тар-мар ителде. Бер самоход орудие, 5 миномет, 30 мичкә бензин, сугыш милекләре төялгән 34 повозка, бер радиостанция һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре һөҗүм сугышлары алып бардылар. Халык яши торган ике пункт районында дошман, совет частьларының алга баруын тоткарларга маташты. Бик каты сугыштан соң немецлар зур югалтуларга дучар булып чигенделәр. Безнең сугышчылар бик күп трофейлар кулга төшерделәр. Икенче бер участокта Н-че часть 540 дошман солдатын һәм офицерын плен алды, 8 орудие, 22 пулемет, 57 автомашина һәм бер сугыш припаслары склады кулга төшерде.

* * *

Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре алга бардылар һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че часть танкистлары дошман оборонасының терәк пунктын тар-мар иттеләр һәм 200 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын кырдылар. 3 танк, 17 орудие һәм 25 автомашина кулга төшерелде. Белая Глина районында безнең частьлар 76 автомашина һәм төрле йөкләр төялгән 246 тимер юл вагоны кулга төшерделәр. Ново-Александровская районында немецларның сугыш милекләре төялгән 3 тимер юл эшелоны кулга төшерелде. Бу милекләр арасында 300 автомашина, 230 мотоцикл, 2 вагон винтовка патроннары, бер вагон винтовкалар, бер вагон пулеметлар, 2 вагон снарядлар, 4 вагон автомоторлар һәм 3 вагон инженерлык милекләре бар.

* * *

Орел өлкәсендә Ворошилов исемендәге отрядның бер группа партизаннары январь урталарында дошманның бер эшелонын юлдан чыгарганнар. Бер паровоз, сугыш припаслары төялгән 18 вагон һәм ягулык тутырылган 6 цистерна җимерелгән. Икенче бер отрядның партизаннары немецларның бер район үзәгендәге гарнизонына һөҗүм иткәннәр. Совет патриотлары 200 гә якын гитлерчыны кырып ташлаганнар. 9 төзек пулемет, 64 винтовка, берничә мең патрон, бик күп киемнәр һәм башка әйберләр кулга төшерелгән.

* * *

Ростов өлкәсе, Нестеркин хуторында торучылар немец-фашист кабахәтләренең гражданнар халкын талаулары, көчләүләре һәм мыскыллаулары турында акт төзеделәр. Актта болай диелә: «Немецлар килгәнчегә кадәр без таза тормышта бәхетле яши идек. Безнең ашлыгыбыз, яшелчәбез күп иде, һәрбер колхозчы тәэмин ителгән иде. Гитлерчылар безне бөтен нәрсәдән мәхрүм иттеләр. Алар колхоз кырларындагы бөтен уңышны талап алдылар. Шулай ук йорт тирәләрендәге участокларга утыртылган барлык нәрсәләр Германия армиясенеке дип игълан ителде. Безгә үз бакчабыздан бер генә кыяр өзү дә тыелды. 4 ай эчендә бандитлар халыктан 300 дуңгызны, 20 атны, 13 үгезне, 1.000 нән артык йорт кошларын талап алдылар. Солдатлар өйләргә бәреп керделәр һәм ит, май, сөт, кием-салым әйберләрен таладылар. Гитлерчылар крестьяннарга карата тән җәзалары керттеләр. Йомыркаены вакытында тапшырмасаң 15 камчы; колхозчы үзенең тавыгын суйса 25 камчы; дуңгыз баласын теркәтмәсәң 25 камчы. Фашист палачлар безнең колхоз председателе Николай Голевны үтерделәр. Чигенер алдыннан немецлар барлык кызларны Германиягә каторгага алып китмәкче булдылар, ләкин Кызыл Армия килеп җитте һәм безне фашистлар коллыгыннан азат итте». Актка М. Воробьева, А. Марченко, Ф. Антипов һәм хуторның башка колхозчылары кул куйды.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (Үзәк фронт). Рәсемдә: чаңгычылар отряды төнге маршта. ТАСС фотохроникасы.

СНАЙПЕР ЗАКИР ГАЙФУЛЛИН

Снайпер Закир Гайфуллин сугышка кадәр үк үзенең киң күкрәгендә, горурлык һәм шатлык белән, «Ворошиловча атучы» значогы йөртә иде. Һәм ул:

—Снайперлык—зур эш ул, снайпер—дошман өчен дәһшәт, снайперлык —гүзәл һәм данлы сыйфат булу өстенә, ул, үткен күз, үткен колак, көчле ихтыяр һәм зур хәйләкәрлек таләп итә,—дип бик еш сөйли иде...

Закир горур һәм киң Себер буйлап, данлы һәм биек Урал таулары аркылы, бөек Россиянең терекөмеш бильбавы—данлы Идел аркылы, туган илнең очы-чиге күренмәс иркен җире буйлап меңнәрчә, меңнәрчә чакырымнарны тимер юлда үтеп бөек сугыш утына килеп керде. Ул, күп сугышларда булды, күп тапкыр һөҗүмгә, атакага барды, нинди генә авыр шартларда да ул һаман корыч рухлы һәм нык булып калды.

Бер вакыт аңа бер кызылармеец бик кызык кына итеп сорау бирде:

—Иптәш Гайфуллин, синең күкрәгеңдә «Ворошиловча атучы» значогы бар икәнләбаса, син, малай, бик яхшы атасыңдыр алай булгач, ә? Тикмәгә генә түгелдер ул, ә?

Гайфуллин моңа чаклы, хәтта үзенең значогын да онытkан иде, ул кайнар һәм шау-шулы көчле сугышларда булса да, төз һәм яхшы атып, бик күп немец бандитларын кырып салса да, ничектер ул үзен әле снайпер дип тә санамый иде.

Менә шул кечкенә генә һәм әйтергә кирәк, очраклы гына бер сорау—Закирны тирән уйларга төшерде. Һәм ул фронтта атаклы снайпер булу теләге белән яна башлады.

Сугышканга — мәйдан бар, дәрте барга—дәрман бар. Гайфуллинның мәйданы да киң иде, дәрманы да күп иде. Ул мылтыгын алды да политработник Егоров белән бергә, үзебезнең оборонаның алгы кырыена килде һәм көн буена диярлек немец позициясен күзәтеп торды.

Ялангач, янган, сынган, шәрә агачлар моңсу полоса булып җәелеп ята... Бу—алгы позиция. Теге якта исә немец хөкем сөрә. Әнә бит алар йөриләр, әнә бит алар безнең халәл җирне таптап, үзләрен хуҗа кебек ничек иркен һәм тыныч тотарга маташалар. Алай гына да түгел, безнең саф кечкенә генә елгада үзләренең шакшы аяк чолгауларын юалар да, безнең нечкә билле зифа талларыбызга кибәргә эләләр.

—Тәвәккәл иттем. . Атам! —дип үзүзенә генә әйтеп куйды Закир һәм акрын гына мылтыгының чакмасына басты... Бу көн Закир көн буе немец солдатларын чүпләп атты. Бу көн ул 12 немец оккупантын юк итте.

—Башланды...

Шул матур җәйге көндә Закир Гайфуллинның чын-чыннан снайперлык тормышы, авыр һәм изге, уңышсызлыклар булганда көендерә торган, яхшы нәтиҗә булганда сөендерә торган чын-чыннан снайперлык тормышы башланды. Ул, күкрәгенә тыйнак кына беркетелеп куелган «Ворошиловча атучы» значогын үзенең уңышлы һәм шатлыклы эшләре белән нурлады, ул значок аңар хәзер мактаулы бер билге булып, алтын орден булып күренә башлады.

Закир снайпер гына түгел, ничектер ике-өч снайпер булырга, әкиятләрдәгечә гадәттән тыш төз атучы булырга теләде һәм ул моңа өйрәнергә, ләкин кәгазь мишеньгә атып түгел, тере фашистка атып өйрәнергә теләде. «Тырышкан ир табар, ташка кадак кагар» дигәннәр безнең бабаларыбыз. Закир тырыш ир иде һәм ул тапты, ул ташка да кадак какты...

Көннәрнең берендә Закир, үзеннән ярты километр җирдә, немец солдатының берничә граната тотып, куаклык буеннан барганын күреп кала. Закир үзенең беренче пулясын фашистның үзенә түгел, аның кулындагы гранаталарга төзәп ата. Гаҗәпкә каршы, гаять кызык хәл була: пуля гранаталарга барып тия, фашист теткәләнеп, чүпрәк һәм сөяккә әверелеп, агач ботагына килеп куна һәм төтен булып җилгә, оча...

Аю һәм кеше турында бер әкият бар. Аюны күрү белән кеше, үлгән булып, җиргә ята. Аю килә, исни дә, кешене үлгән дип санап, китеп бара һәм шулай итеп кеше исән кала. Закир белән дә шуңа охшаш бер хәл булды, Закир исән калды, немец исә аюдан да битәр алданды, Закир аны бер ату белән теге дөньяга җибәрде...

Ул вакыйга менә ничек булды:

Закир ничектер ачык урында калган иде. Һәм ул дошман снайперына, уч өстендә торган кебек, нәкъ күз алдында торган кебек, бик ачык күренә иде. Немец атты, атты, ләкин бәхеткә каршы пулялар Закирга тими үтте. Закир, башка чара булмагач, үлгән булып бик озак ятып торды һәм немец снайперының күренүен көтеп торды. Күп тә үтми, немец үзенең оясыннан чыгып, бөгелә-сыгыла куаклык арасына чаба башлады. Закир, яхшы гына төзәп. атып җибәрде..: Немец җиргә ауды. Ләкин Закир гадәттәгечә, моңа сөенмәде, һәм үзенең «хисап» блокнотына теркәп куярга да ашыкмады. Дөрес, ул җиңде, ләкин ул сакчылык һәм маскировка тәртибен бозганлыгы өчен бик нык итеп үз-үзен орышты. Ул бу немецны «хисап» ка санамаска, башка вакытта оста яшеренергә, хәйләкәр булу һәм нинди генә мәкерле һәм хәйләле немецны да кәкере каенга сөяү өчен өйрәнергә, тырышырга карар итте.

Закир Гайфуллин үзенең сугышчан тормышын сөйләгәндә аеруча бер кызык хәлне бик еш искә төшерә һәм бу турыда зур күтәренкелек белән сөйли башлый:

—Бер вакытта мин, дошманны көтеп ятмаска, бәлки дошманны эзләргә кирәк, дип үз-үземә карар бирдем дә, урман һәм сазлык аркылы бер-ике километрга—немецлар ягына чыктым. Әйе. Яхшы аланлык. Тавыш-тын юк. Әйе. Менә бер вакыт, син күр дә мин күр, сукмак буйлап биш солдат белән бер немец офицеры килә. Әйе. Ярый, мәйтәм. Алар килделәр дә, миңа ерак кына түгел җирдә капылт туктап калдылар. Ярый мәйтәм, әйе. Офицерга төзәдем дә—гөрс! Әйе. Офицер егылды. Солдатлар аптырап калдылар. Алай да алар «батырлар» икән, офицер яныннан китмиләр. Әйе. Берсе офицерның наганын алып кесәсенә тыкты, берсе сәгатен сукты. Немецлар качып китә башладылар. Төзим дә — «гөрес», төзим дә— «гөрес». Алай да берсе китте әй. Һи, китәме соң ул! Үләксә яныннан карганың тиз генә киткәнен кайда күргәнең бар? Килде бит немец тагын. Кесәләрен актарырга тотынды. Әйе. Әйдә, мин әйтәм, бае фриц! Рәхәтлән, дим. Теге китә генә башлаган иде, аттым да—немец егылды шул. Әйе, ярый, мин әйтәм, шәп, шәп булды бу.

Подразделение каршында бер вакыт зур уңайсызлык туа. Немец батальоны урманның ике кварталын бүлгән, ачыклык полосаның үзләре янындагы башына пулемет куйган. Бу хәл исә, безнең сугышчыларга шул ачыклык полоса аркылы үтәргә мөмкинлек бирми иде. Андагы пулеметны һәм андагы фрицларны юк итәргә һәм подразделение өчен йөрер юл ачарга кирәк иде. Закир шул полосада атналар буена ятты, байтак немец фашистын юк итте, немецлар курыктылар, шуннан соң инде анда пулемет куймый башладылар.

Закир Гайфуллин атаклы снайпер булып китте. Командование аңа бүләк итеп снайпер мылтыгы бирде, аның үзенең берничә өйрәнчеге дә булды инде. Командование аны махсус снайперлар отделениесенең командиры—җитәкчесе итеп билгеләде.

Гайфуллинның хисабында —59 үтерелгән немец. Аның иптәшләре укучыларыннан—Абдерахманов хисабында—19, Гобеденюк хисабында—32, Сердюков хисабында—9, Шатенко хисабында—12 үтерелгән немец санала. Менә шул кечкенә бер группаның хисабы һәм аның шөһрәте бертуктаусыз көннән көн үсә һәм үсә башлый. Гайфуллин берләшмә күләмендә җыелган снайперлар слетына бара һәм ул аннан кайткач та тагын да зуррак дәрт һәм күтәренкелек белән үзенең сөйгән эшенә кереп чума.

Татар халкы үзенең Гайфуллин Закир кебек атаклы каһарман уллары белән мактана. Безнең бөек ватан үзенең улларын сугыш кырында батыр, чыдам, туры һәм җитез сугышчылар итеп тәрбияли. Безнең ватан үзенең батыр улларын хөрмәтли һәм аларның батырлыкларын тәкъдир итеп, лаеклы рәвештә бүләкли. Закир Гайфуллин «Батырлык өчен» медале алды. Алай гына да түгел, ул, бу бүләк белән бергә, туган илнең бөек хөрмәтен һәм мактавын алды.

Хәзер Гайфуллинның күкрәгендә «Ворошиловча атучы» значогы белән янәшә, көмеш медаль—«Батырлык өчен»медале балкый. Бу ике билге аны тагын да бөек җиңүләргә, бөек уңышларга чакыра.

ШӘРӘФ МӨДӘРРИС.
Хәрәкәттәге армия.

СУГЫШ САМОЛЕТЛАРЫ ЭСКАДРИЛЬЯЛӘРЕН КҮБРӘК БИРИК!

АЙ ЯРЫМЛЫК ХЕЗМӘТ ХАКЫ КҮЛӘМЕНДӘ

«Светоч» фабрикасы коллективы батыр кызылармеецларга бүләккә, шулай ук эскадрильяләр төзүгә 61 мең сум акча җыеп тапшырды. Һәрбер эшче уртача бер айлык хезмәт хакын бирде.

Иптәш Благов (бондарь) 400 сум хезмәт хакы ала. Ул 900 сум бирде. Иптәш Мансурова хезмәт хакының ярты айлык күләмен бүләккә, ай ярымлык күләмен эскадрилья төзүгә тапшырды.

* * *

«Кызыл Шәрык» заводы коллективы Кызыл Армиянең геройларча һөҗүм итүләрен зур күтәренкелек белән каршы алып, эскадрилья төзү һәм батыр кызылармеецларга бүләкләр әзерләү өчен акчалар җыю эшен көннән-көн уңышлы дәвам итә. Шушы көнгә бүләкләр өчен 44.104 сум, эскадрилья төзү өчен 106.389 сум акча җыелып, 80.000 сумы Дәүләт банкысына кертелде дә инде. Эшче һәм хезмәткәрләрнең күпчелеге бүләкләргә һәм авиаэскадрильяләр төзү фондына айдан артык хезмәт хакларын бирде.

Уборщица иптәш Даниллованың ире һәм 2 улы—фронтта. Ул авиаэскадрильяләр төзүгә һәм бүләкләргә ике ай ярымлык хезмәт хакы күләмендә акча кертте.

Стахановчы иптәш Водянованың ире фронтта, кулында ике баласы тәрбияләнә. Аның айлык хезмәт хакы 300 сум. Ул, бүләкләр өчен 150 сум, эскадрилья төзүгә 350 сум бирде. Айлык хезмәт хакы 150 сум булган иптәш Собакова бүләкләр өчен 250 сум, эскадрилья төзүгә—750 сум тапшырды. 200 сум хезмәт хакы алучы иптәш Билалетдинова бүләкләр өчен 200 сум һәм эскадрилья өчен 300 сум бирде.

КОЛХОЗЧЫЛАР АКТИВЛЫГЫ

ТЕЛӘЧЕ, 28 январь. **(Телефон буенча).** Мәтәскә авыл советына караган «Комбайн» һәм «Кызыл юл» колхозы членнары самолетлар эскадрильясы төзү фондына средство туплауда актив катнашалар. Бу авыл советына караган колхозларның членнары ике көн эчендә генә дә самолетлар эскадрильясы төзү өчен 81.000 сум акча тупладылар.

Авыл советы председателе Шәмсетдинов һәм агитаторлардан Шамаров иптәшләр колхозчылар арасында масса-аңлату эшләрен бик яхшы алып баралар.

* * *

ЧЕПЬЯ, 28 январь. (Телефон буенча). «Бакча» колхозы председателе иптәш Әскәров самолетлар эскадрильясы төзү фондына 50.000 сум һәм «Труд» колхозы председателе иптәш Шапошников 13.000 сум акча керттеләр.

АЙЛЫК ПЛАН ЯРТЫ АЙДА ҮТӘЛДЕ

«Светоч» фабрикасының карамель һәм конфект цехлары январь ае планын 16 нчы январьга ук 103 процент итеп үтәделәр. Хәзер алар планнан тыш бик күп өстәмә продуктлар эшләп чыгаралар.

Фабриканың барлык цехларында да Кызыл Армиянең 25 еллыгына багышланган социалистик ярыш договорлары төзелде. Ярышта конфект цехы алда бара. Сафиуллина һәм Кузнева иптәшләрнең бригадалары көнлек нормаларын 200 һәм 230 процентка үтәп килә-ләр.

1943 НЧЕ ЕЛДА ЮГАРЫ ИГЕН УҢЫШЫН ЯУЛАП АЛУ ӨЧЕН ФРОНТКА ЯРДӘМЕБЕЗНЕ КӨЧӘЙТИК!

Октябрь районы, „Үрнәк“, „Ерепкино“ һәм „Красная Гора“ авыл хуҗалыгы артельләре колхозчыларының хаты

Бөек Ватан сугышы фронтларыннан килә торган хәбәрләр барлык совет патриотларын шатландыра. Безнең данлыклы сугышчыларыбызның басымына фашистлар өере чыдый алмады. Кызыл Армия шәһәрләрне һәм авылларны бер-бер артлы немец басып алучылардан тазартып, алга һәм алга бара. Без, дошманны тиздән тәмам җиңәчәгебезгә ышанабыз һәм бу сәгатьне якынайту өчен, колхоз производствосында үз-үзебезне аямыйча эшлибез, армый-талмый фронтка ярдәм итәбез.

Үткән елны без яхшы уңыш алуга ирештек. «Үрнәк» авыл хуҗалыгы артелендә һәрбер гектардан 15 центнер уңыш алынды. Калинин исемендәге колхозда һәр гектардан 100 поттан артыграк уңыш алынды. Дәүләткә ашлык тапшыруны срогыннан элек үтәдек. Шуның өстенә безнең колхозларыбызның һәрберсе мәҗбүри тапшырулардан тыш Кызыл Армия фондына 1.200 әр пот ашлык тапшырды.

Хәзер 1943 нче елда югары иген уңышы өчен көрәш киң җәелде. Язгы чәчүгә үрнәк төстә әзерләнү өчен күп көч куярга кирәк. Колхозчылар чәчүлек орлыклары турында зур кайгыртучанлык күрсәтәләр. Игеннең уңышы әнә шул чәчүлек орлыкларына бәйләнгән. «Үрнәк» колхозында чәчүлек материаллары туплау планы арттырып үтәлде. Биредә чәчүлек орлыклар бөтенләй сортланды һәм кондициягә җиткерелде. 63 яшьлек колхозчы Әхмәтҗан Вафин чәчүлек материалларын һәрвакыт күзәтеп торуны үз өстенә алды. Ул орлыкларны сортлауны бик нык тикшереп торды, ә хәзер амбарларда орлыкның ничек сакланганлыгын һәркөн тикшереп тора.

«Красная Гора» авыл хуҗалыгы артеле колхозчылары агротехниканы тулысынча кулланырга карар бирделәр. Хәзер анда җирле ашламалар әзерләнә. Кырларга 2.600 йөктән артык тирес чыгарылды. Һәрбер комсомолецка кимендә 2 центнер көл җыярга задание бирелде. Һәрбер бригада ашламалар әзерләү һәм кырга тирес чыгару буенча колхоз правлениесеннән план алды. Беренче бригаданың бригадиры Петр Кирьяшин заданиене арттырып үтәп килә. Аның бригадасындагы барлык колхозчылар көл һәм кош тизәге җыялар һәм саклыйлар.

«Үрнәк» колхозында 150 гектар мәйданда кар тоту уңышлы рәвештә үткәрелде. Карның калынлыгы 60—70 сантиметрга җитте инде.

Һәрбер колхозда ремонт бригадалары оештырылды. «Ерепкино» авыл хуҗалыгы артелендә тимерче Гаврил Питимиркин армый-талмый эшли, аны көндезен дә, кичен дә тимерче мастерскоенда күрергә мөмкин. Күптән түгел ул 5 чәчү машинасына, 10 культиваторга, 48 тырмага, 15 сабанга һәм башка инвентарьга ремонт ясалганлыгы турында колхозчыларга белдерде.

«Ерепкино» авыл хуҗалыгы артелендә агротехника укулары яхшы оештырылды. Хата-лаборатория мөдире Иван Кудрявцев кадрларны белеп әзерли. 23 кеше даими рәвештә авыл хуҗалыгы машиналарын өйрәнәләр. Тиздән алар билгеләнгән программаны тәмам итәчәкләр.

Язгы чәчүдә ат хәлиткеч рольне уйнаячак. Шунлыктан ат турында бик нык кайгыртучанлык күрсәтергә кирәк. «Үрнәк» колхозында һәрбер ат караучыга берәр группа атлар беркетелде, алар өчен тупас азыклар һәм концентратлар бүленеп куелды. Ат караучылар бөтен тәүлек буена атлар янында торалар. Яхшы тәрбияләү аркасында барлык атлар уртача һәм уртачадан югары көрлектә.

Язгы чәчүне кыска срокларда, югары агротехника дәрәҗәсендә үткәрү—безнең сугышчан заданиебез. Без аны шулай итеп үткәрәчәкбез дә. Безнең районның колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзелешенә 2.538 мең сум акча туплаган өчен, Кызыл Армия фондына 12.566 пот ашлык һәм промышленность эшчеләре өчен 4.000 пот ашлык тапшырган өчен, иптәш Сталиннан туганлык сәламе һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен алдылар. Бу безнең өчен гаять зур шатлык булды.

Иптәш Сталинның котлавы безне яңа хезмәт батырлыкларына рухландырды. Хәзер безнең районның барлык колхозларында язгы чәчүгә әзерлек буенча киң һәм актив эш җәелеп китте. Орденлы Татарстанның барлык колхозчыларын үз-үзләрен аямыйча эшләргә, язгы чәчүгә үрнәк төстә әзерләнергә, аны уңышлы итеп үткәрергә чакырабыз. Данлыклы сугышчыларыбызның һөҗүменә булышлык күрсәтү өчен, югары иген уңышын яулап алу өчен көчләребезне кызганмыйк, фронтка һәм илгә икмәкне, итне, промышленность өчен чималны күбрәк бирик.

Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!

Октябрь районы, «Үрнәк», «Ерепкино» һәм «Красная Гора» авыл хуҗалыгы артельләре колхозчыларының тапшыруы буенча колхоз председательләре—**ГАЙНУЛЛИН, Н. КРАСНОВ, В. КВАШИН.**

Татарстан АССР Совнаркомында

1 нче МАЙ РАЙОНЫНДА АШЛЫК ӘЗЕРЛӘҮНЕҢ БАРЫШЫ ҺӘМ АШЛЫКНЫ ЭЧКӘРЕ ПУНКТЛАРДАН ТАШУ ТУРЫНДА

Татарстан АССР Совнаркомы 1 нче Май районы колхозларында ашлык әзерләүнең барышы турындагы мәсьәләне тикшерде. Үткән елгы ашлык әзерләү планы районда быел 20 нче январьга бары 31,6 процентка гына үтәлгән. Эчкәре пунктлардан юл буйларына ашлык ташу чиктән тыш акрын бара. Авыл хуҗалыгы продуктларының башка төрләре буенча да дәүләт каршындагы йөкләмәләрне үтәү эше начар тора. 10 нчы январьга бәрәңге тапшыру планы бары 38,8 процентка гына, сөт тапшыру 51,2 процентка һәм ит тапшыру планы 89,9 процентка гына үтәлгән. Печән, киндер орлыгы һәм сус тапшыру заданиеләре дә бик күп үтәлми калган.

Совнарком мондый хәлнең район советы башкарма комитеты председателе Юсуповның гафу ителмәслек дәрәҗәдә гамьсезлеге һәм җавапсыз караштa булуы аркасында килеп чыкканлыгын күрсәтеп үтте.

Районда 7.000 гектардан артык хуҗалык чәчүлекләре һәм орлыклык участоклар мәйданыннан алынган ашлыкны сугу әле һаман да тәмам булмаган. Чәчүлек материал салу һәм әзерләү акрын бара. Башкарма комитет председателе Юсуповның гадәттән тыш начар эшләве һәм аның юл куюы нәтиҗәсендә 1 нче Май районы колхозларында дәүләткә каршы практика киң күләмдә җәелгән.

Колхозларның күпчелегендә СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының игеннәрне урып җыю һәм авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләү турындагы карарының колхозчыларга аванс бирү турындагы өлеше тупас рәвештә бозылган, колхозларның эчке кирәкләренә ашлык күп тотылган, партия һәм хөкүмәт карарларына каршы килеп, чәчүлек орлык фондларына дәүләт каршындагы йөкләмәләрне үтәгәнчегә кадәр гомуми чәчүлекләрдән алынган ашлыкны салу практикасына юл куелган. Сугылган ашлыкны яшерү фактлары булган. «Үтәмеш» колхозында 117 центнер ашлык приходка кертелмәгән, Ильич исемендәге колхозда 393 центнер ашлык исәпкә алынмаган һәм колхозның эчке кирәкләренә тотылган.

Татарстан АССР Совнаркомы хезмәт ияләре депутатларының 1 Май район советы башкарма комитеты председателе С. Ю. Юсуповны, ашлык әзрләүне, ашлыкны эчкәре пунктлардан ташуны өзгән өчен, дәүләткә башка төрле авыл хуҗалыгы продуктлары тапшыру планнарын үтәмәгән өчен, саботажникларга юл куйган өчен эшеннән алырга һәм судка бирергә карар бирде. Республика прокурорына бу эшне иң якын арада тикшерергә һәм район колхозларында дәүләткә каршы практикага юл куюда гаепле булган барлык кешеләрне җавапка тартырга тапшырылды.

1 Май районы башкарма комитетына, ашлык әзрләүнең һәм башка төрле авыл хуҗалыгы продуктлары тапшыруның барышы турындагы мәсьәләне район советының чираттагы сессиясендә карарга, 1943 нче елгы язгы чәчүне үткәрүгә әзерлекне тикшерергә һәм райондагы хәзерге хәлне тамырыннан үзгәртү өчен барлык кирәкле чараларны эшләргә һәм иң якын араларда тормышка ашырырга кушылды.

Зур уңышлар белән

ЧИСТАЙ, 27 январь. (Телефон буенча). «Мәгариф» колхозында, Кызыл Армиянең 25 еллыгын зур уңышлар белән каршылау өчен социалистик ярыш киң җәелдерелде. Социалистик ярыш йөкләмәләрендә язгы чәчүгә әзерлек эшләре турындагы пунктлар төп урынны алып торалар. Алынган йөкләмәләрнең үтәлеше язгы эшләргә әзерлекнең гүзәл нәтиҗәләрен бирә.

Колхозда 81 тырмага, 8 чәчү машинасына, 12 культиваторга һәм 35 сабанның 13 нә ремонт ясалды инде. 67 сука камытының 37 се төзәтелде. Ремонтта эшләүчеләрдән Вәлиев һәм башка иптәшләр норманы 160—180 процентка җиткереп үтиләр. Мингалим бабай да ремонтта үзенең эшен намус белән үти.

Басуга тирес чыгару һәркөнне дәвам итә. 1.150 йөк тирес чыгарылды инде. 8 тонна көл һәм 28 центнер кош тизәге җыелды. 114 гектар мәйданда кар тотылды.

Агротехник өйрәтүләр дә яхшы оештырылган. Колхозның агротехнигы иптәш Закиров агротехник укуларны бик яхшы алып бара.

Хәзерге вакытта колхоз чәчүлек орлыкларны чистартып бетерүгә нык әһәмият бирә. 400 центнер бодай әзерләп куелды инде. Ашлык чистартуда эшләүчеләрдән Галимова, Баһаветдинова һәм Велиева иптәшләр үзара ярышып, бик тырышып эшлиләр.

Ш. ШАКИРОВ.

СВОДКА

ТАТАРСТАН АССР МТС ЛАРЫНДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

1943 нче ЕЛНЫҢ 25 нче ЯНВАРЕНА
(ПЛАНГА КАРАТА ПРОЦЕНТЛАРДА)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
1. Мөслим	95,7	38. Чыбыклы	53,3	74. Буденный	35,1
2. Нөркәй	94,3	39. Әлмәт	52,1	75. Теләче	31,7
3. Тымытык	91,9	40. Тәтеш	52,1	76. Маткауш	34,5
4. Чокалы	90,9	41. Аксубай	50,0	77. Салман	34,2
5. Бәгелмә	83,0	42. Зирекле	50,0	78. Тәкәнеш	34,0
6. Ишеево	82,9	43. Мөслим (Чистай)	50,0	79. Питрәч	34,0
7. Тирсә	82,5	44. Б. Матак	49,0	80. Столбище	33,3
8. Чүпрәле	79,1	45. Димитров	48,6	81. К. тамагы	33,3
9. Алабуга	75,0	46. Баулы	48,1	82. Минзәлә	32,6
10. Саба	74,0	47. Ютазы	48,0	83. Арча	32,6
11. Норлат	66,7	48. Бондюг	46,7	84. Макыл	32,0
12. Октябрь	65,5	49. Юдино	46,7	85. Биләр	31,7
13. Алга	65,0	50. Куйбышев	45,6	86. Морт	31,4
14. Юртыш	64,3	51. Иске Тимошкино	45,6	87. Казанбаш	30,3
15. Тархан	63,9	52. Кичү	45,2	88. Чишмә	30,3
16. Заинский	63,8	53. Балтач	44,2	89. Шөгер	30,2
17. Мөрәле	63,8	54. Каргалы	43,3	90. Б. Бистәсе	30,0
18. Чистай	62,7	55. Иске Чишмә	43,2	91. Ромадан	29,6
19. Сарман	62,3	56. Исәнбай	43,2	92. Майдан	29,3
20. Зөя	61,9	57. Тельман	42,6	93. Әлши	28,6
21. Актаныш	61,4	58. Буа	42,6	94. Константиновка	26,9
22. Янильи	61,4	59. Калинин	42,0	95. Трехозерский	26,4
23. Соколка	60,8	60. Чаллы	41,8	96. Кузнечиха	25,4
24. Кызыл чапчак	60,7	61. Черемуховский	40,7	97. Биектау	25,0
25. Азин	59,5	62. Чалпы	40,5	98. Тат. Ялтан	24,2
26. Дәүләки	58,7	63. Әтнә	40,0	99. Үзәк	23,5
27. Поповка	58,5	64. Рождественский	39,1	100. Мамадыш	22,6
28 Кызыл йолдыз	58,3	65. Иске Писмән	38,3	101. Әлки	17,9
29. Кузайкино	58,2	66. Акташ	37,9	102 Кошкино	17,4
30. Олы Кариле	58,0	67. Яңа Чишмә	37,3	103 Тат. Ходяш	16,7
31. Чүрибураш	57,4	68. Алексеевский	37,0	104. Зур Поляна	15,8
32. Кодряк	56,8	69. Карамалы	36,4	105. Чиябаш	11,1
33. Дөбъяз	56,2	70. Кәкрә елга	36,1	106. Ключи	10,3
34. Мәлки	56,0	71. Кызыл юл	35,6	БАРЛЫГЫ:	46,0
35. Беренче Май	54,9	72. Әхмәт	35,3	1943 нче елның 20 нче январена	43,7
36. Т. Тамак	53,8	73. Солтан	35,3		
37. Кукмара	53,6				

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

28 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

28 нче январьда безнең гаскәрләр кискен атакадан соң Касторное шәһәрен һәм зур тимер юл узелын алдылар.

Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре Курганная район үзәген һәм тимер юл узелын, **Ново-Покровская** район үзәген һәм тимер юл станциясен, **Гулькевичи** район үзәген һәм тимер юл станциясен, **Калниболотская, Ильинская** район үзәкләрен, халык яши торган зур пунктлардан: **Петропавловскаяны, Михайловскаяны** һәм тимер юл станциясе **Отрадо-Кубанскоены** алдылар.

Баренц диңгезендә безнең корабльләр дошманның 8.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырдылар.

* * *

27 нче январьда безнең частьлар фронтның төрле участокларында немецларның 5 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 5 артиллерия батареясының утын бастырдылар, бер тимер юл эшелонын һәм 4 паровозны җимерделәр, бер батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

Дон фронты гаскәрләре гитлерчыларның таркау группаларын кыруны дәвам иттерделәр. Бер участокта дошманның бер батальон пехотасы юк ителде. 300 немец солдаты һәм офицеры плен алынды. Сталинградтан төньяктарак плен алынган 3 немец, кире үз частьлраына җибәрелгәннән соң, озак та үтми яңадан әйләнеп килделәр һәм үзләре белән бергә коралларын ташларга карар биргән тагын 70 солдат һәм офицерны алып килделәр. Безнең подразделениеләр 97 пулемет, 100 дән артык автомашина, 12 паровоз һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Көньяк фронт гаскәрләре һөҗүмне дәвам иттерделәр, ә көчләренең бер өлеше белән дошман танкларының һәм пехотасының контратакаларын кире кайтардылар. Бер участокта немецлар халык яши торган пунктларны көчле оборона узелларына әйләндергәннәр һәм совет гаскәрләренең алга баруларына тоткарлык ясарга маташалар. Безнең частьлар, дошманның каршылык күрсәтүен бастырып, немецларның күп санлы ныгытмаларын юк итәләр һәм аларның җанлы көчләрен бик күп югалтуларга дучар итәләр.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронт гаскәрләре элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар. Н-че артиллерия подразделениесе, пехота частьларының хәрәкәтләренә булышлык итеп, дошманның 2 артиллерия батареясының утын бастырды һәм 6 танкысын юк итте. Икенче бер участокта безнең бер частебыз халык яши торган бер пунктны алды һәм 2 орудие, бер бронемашина, 17 пулемет, бер ягулык склады һәм башка трофейлар кулга төшерде. 46 немец солдаты һәм офицеры плен алынды.

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр. Н-че танк часте дошман гаскәрләренең чолганып алынган группасының каршылык күрсәтүен бастырды. 300 гә якын дошман солдатлары һәм офицерлары кырып ташланды, 730 кеше плен алынды. Безнең укчы частьларыбыз алга барган чакта халык яши торган берничә пунктны гитлерчылардан азат иттеләр һәм бер батальонга якын немец пехетасын юк иттеләр. 6 орудие, 7 бронетранспортер, алты көпшәле 2 миномет, әйбер склады һәм азык склады кулга төшерелде.

* * *

Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре уңышлы рәвештә алга бардылар һәм халык яши торган күп кенә зур пунктларны алдылар. Н-че часть сугышчылары бер көн эчендә дошманның 200 солдатын һәм офицерын юк иттеләр, 9 танкысын һәм 17 автомашинасын зарарладылр һәм яндырдылар. Артиллерия һәм миномет уты белән дошманның моторлаштырылган бер батальоны таркатылды һәм бер өлеше юк ителде. Гвардияче кавалеристлар дошман тылына барып чыгып, шоссе юлы буйлап чигенүче немец пехотасына көчле атака ясадылар. 300 дән артык гитлерчы кырып бетерелде, пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Украинаның бер районында хәрәкәт итүче, Хрущев исемендәге партизаннар отряды кинәт зур тимер юл станциясенә һөҗүм иткән. Совет патриотлары сакчыларны үтергәннәр, станциядә булган бер паровозны һәм бер дрезинаны шартлатканнар. «За родину» исемле партизаннар отряды, икенче бер тимер юл станциясенә һөҗүм итеп, станциянең хуҗалыгын җимергән һәм күп винтовкалар, патроннар һәм гранаталар кулга төшергән.

* * *

Түбәндә Воронеж өлкәсенең Вторая Бугаевка авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән коточкыч ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Немецлар авыл халкын мыскылладылар һәм мәсхәрәләделәр. Алар безне бер дә ял итмичә юллар төзәтүдә һәм чистартуда эшләргә мәҗбүр иттеләр. Җәй ахырында авыл якынында бер немец офицерының үле гәүдәсе табылган иде. Гитлерчы бандитлар беренче очраган 20 кешене тотып алып амбарга бикләделәр. Аларны озак газапладылар һәм җәзаладылар. Палачлар 16 кешене атып үтерделәр, ә калган 4 колхозчыны бөтен халык алдында асып куйдылар. Чигенгән чакта немецлар 35 йортны, авыл советы бинасын, ике мәктәпне, уку өен, колхозның ат дворын һәм башка каралтыларны яндырдылар. Балалары белән берлектә хатыннар керәп качкан базларга һәм чокырларга фашист ерткычлар гранаталар ыргыттылар». Актка Гахова, Бугаева һәм башка колхозчылар кул куйды.



Рәсемдә: Американың «Генерал Стюарт» типындагы җиңел танкларын төягән поезд Мисырда. Бу танклар Роммель армияләренә каршы сугыш операцияләрендә катнаштылар.

Триполитаниядә Англия гаскәрләренең һөҗүме

ЛОНДОН, 27 январь. (ТАСС). Генерал Леклерк командалыгындагы француз гаскәрләре штабы Леклеркның алгы частьларының кичә Триполига кергәнлекләрен хәбәр итә.

Англия информация министрлыгының хәбәр итүенә караганда, 25 нче январьда Англиянең алгы частьлары яр буендагы юл буйлап кына түгел, бәлки фронтның башка участокларында да Триполидан көнбатышка таба алга киткәннәр. Монтгомери гаскәрләре, Триполидан көнбатышка таба алга барып, Триполины алганчыга кадәр үк очрарга туры килгән кыенлыкларга очрыйлар. Аларга миналар куелган юллардан үтәргә туры килә. Шуның өстенә бу юллар күп урыннарда җимерелгәннәр. Дошманның арттагы сафлары Англия гаскәрләренә шактый каршылык күрсәтәләр.

Союзниклар авиациясе, Меденидагы һәм Бен Гардандагы базаларны битараф калдыру максаты белән һәм Триполига һавадан булган куркынычны бетерү өчен күчәр державаларының самолетлар төшә торган алгы площадкаларын бетерү максаты белән дошманның андагы авиация базаларын бик нык бомбага тота.

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенчә, Кастель Бенитоны алган чакта 8 нче армия күчәр державаларының 200 самолетын кулга төшергән. Шулардан 30 самолетны хәзер үк файдаланырга мөмкин.

Англиянең сугыш расходлары

ЛОНДОН, 27 январь. (ТАСС). Англиянең финанс министры Кингсли Вудның түбәнге палатада ясаган белдерүенә караганда, Англия сугышка көн саен 14 миллион фунт стерлинг чамасы расход тота. Күптән түгел генә әле бу расходлар 1 миллион 250 мең фунт стерлингка кимрәк булганнар. Расходларның артуы Төньяк Африкадагы операцияләргә һәм Англиядән читтәге башка сугыш хәрәкәтләренә бәйләнгән. Бюджет буенча еллык расход моннан элек билгеләнгән 4 миллиард 500 миллион фунт урынына 4 миллиард 900 миллион фунт чамасы итеп билгеләнгән.

Түбәнге палата сугыш кирәкләренә 1 миллиард 900 миллион фунт стерлинг күләмендәге яңа кредитларны бер тавыштан раслаган.

ИТАЛИЯ ПАРОХОДЫНДА ЯНГЫН

ЖЕНЕВА, 25 январь. (ТАСС). Швейцариядә чыга торган «Нейе цюркер цейтунг» газетасының хәбәр итүенә караганда, Италиянең Венеция гаванендә туктап торган «Сатурина» исемле зур пароходында янгын чыккан. Янгыннан 2 миллион лира зарар килгән. Бу янгын экипаж членнарыннан берсенең ут төртүеннән чыккан.

Италиянең промышленностенда һәм транспортында саботажның үсүе сәбәпле Муссолини яңа декрет чыгарырга мәҗбүр булган. Бу декрет буенча производствога кечкенә генә зарар китергән кеше дә 24 елга кадәр төрмәгә ябылуга дучар ителәчәк.

ЛЮКСЕМБУРГТАГЫ МЕТАЛЛУРГИЯ ЗАВОДЛАРЫНДА ЗАБАСТОВКАЛАР

НЬЮ-ЙОРК, 27 январь. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгы хәбәрчесенең Мадридтан хәбәр итүенә караганда, 23 нче январьдан башлап Люксембургтагы металлургия заводларында Германиягә продукция җибәрүгә һәм эш көнен тагын да озайтуга каршы протест йөзеннән меңнәрчә эшчеләр забастовка алып баралар. Йөзләрчә кешеләр кулга алынган.

АМЕРИКА БОМБАРДИРОВЩИКЛАРЫНЫҢ ВИЛЬҺЕЛЬСГАФЕНГА ҺӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 27 январь. (ТАСС). Американың Европадагы сугыш операцияләре мәйданындагы хәрби һава көчләре штабының белдерүендә әйтелүенчә, 27 нче январьда көндез Америка бомбардировщиклары Германия территориясендә дошманның хәрби объектларына беренче тапкыр һөҗүм ясаганнар. «Оча торган крепость Б—17» самолетлары Вильһельмсгафендагы хәрби диңгез базасын бик нык бомбага тотканнар.

ГЕНЕРАЛ ДЕ ГОЛЛЬ БЕЛӘН ГЕНЕРАЛ ЖИРОНЫҢ ОЧРАШУЫ

ЛОНДОН, 27 январь. (ТАСС). Англиянең информация министрлыгы Франция Төньяк Африкасында генерал де Голль белән генерал Жиронның беренче очрашуы булганлыкны хәбәр итә. Бу очрашудан соң алар бергәләшеп түбәндәге белдерүне игълан иткәннәр:

«Безнең очрашуыбыз булды. Без фикерләр алыштык. Без Францияне азат итүгә һәм дошманны тәмам тар-мар итү нәтиҗәсендә кешелек азатлыкларының тантанасына кайтып кала торган максатка ирешү ягыннан үзебезнең тулысынча килешкәнлегебезне билгеләдек. Бу максатка үзләренең союзниклары белән бергәләшеп сугышучы барлык французларның сугышта берләшүләре нәтиҗәсендә ирешеләчәк».

Лондонга кайтканнан соң генерал де Голль Африкада президент Рузвельт белән очрашуы турында белдерү ясаган. Генерал болай дигән: «Рузвельтның Франциягә карата дуслык мөнәсәбәте француз халкы тарафыннан аның үз территориясендә дә, шулай ук аннан читтә дә дошманга каршы алып барыла торган көрәштә аеруча күңелле хәл. Мин бу уңай белән Англиянең баш министры белән сөйләшүләрне яңарту мөмкинлегә алуыма да шулай ук канәгатьләндем».

Франциянең милли комитеты игълан иткән белдерүдә болай диелә: «Африкада союзниклар арасында булган конференция уңае белән генерал де Голль, генерал Катру белән һәм контр-адмирал д' Арженью белән берлектә, Франция Төньяк Африкасында генерал Жиро белән очраштылар. Бу очрашу корыда, диңгездә һәм һавада Франциянең хәрби тырышлыкларын һәм кораллы көчләрен берләштерүне тәэмин итү максаты белән үткәрелде. Нәтиҗәдә хәзер үк хәрәкәтләрне берләштерергә кирәклек турында карар кабул ителде. Шуның өстенә, сөйләшүләр вакытында Франциянең Төньяк һәм Көнбатыш Африкасындагы яңа хәлне исәпкә алып, французларның азатлык өчен бара торган сугыштагы тырышлыкларын тагын да үстерергә мөмкинлек бирә торган шартлар каралды. Бу мәсьәлә буенча фикерләр алышу дәвам итәчәк. Генерал де Голль һәм милли комитет, элекке кебек, Франция җирләре, аның кораллы көчләре һәм Франциянең үзендә каршылык күрсәтү көчләре арасында тулы союзның Франция халкының теләгенә һәм дәрәҗәсенә туры килә торган шартларда тормышка ашырылуына тайпылышсыз рәвештә омтылалар».

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Татар дәүләт опера һәм балет театры. Бүген — *„Ильдар“*, 30 нчы январьда — *„Башмагым“*.

Зур драма театры. Бүген — *„Маскарад“*, 30 нчы январьда — *„Минем улым“*. 31 нче январьда көндез һәм кич — *„Маскарад“*,

Дәүләт циркы. Бүген — *зур цирк тамашасы* һәм французча көрәш ярышлары. Кич 8 сәгатьтә башлана

„Электро“ — *„Сиңа сокландым“*.

„Унион“ — *„Котовский“*.

„Пионер“ көндез — *„Ялгыз җилкән күренә“*, кич — *„Антон Иванович ачулана“*.

„Чаткы“ — *„Алтын кул“*.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 31 нче январьда иртә белән — *„Таймасовлар“*, кич — *концерт-бал.* Бөтен җыелган акча оборона фондына биреләчәк.

Зур драма театры. 1 нче һәм 2 нче февральдә — *концерт-бал.* Терле уеннар, аттракционнар, төнге 2 сәгатькә кадәр *танецлар.* Бөтен җыелган акча оборона фондына биреләчәк. Кич 9 сәгатьтә башлана.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. — секретарь—АТС 79—39. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ 627 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 183